**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАСЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422647, с. Масловка,
ул. Центральная, дом 13

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАСЛОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422647, Масловка авылы,
Центр урамы, 13 нче йорт

Тел.: (84361) 253 55, факс: (84361) 253 55, e-mail:Masl.RS@tatar.ru сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 22 гыйнвары Масловка авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымталар нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2023 №01 карарының үз көчен югалтуын таныргa.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Масловка авылы, Центр урамы, 13 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге башлыгы А.И.Егоров

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Масловка  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024 елның  23 гыйнварындагы
1  номерлы карарына
кушымта  №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең  аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны  һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5929,40 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга)  күчерү  (алып бару) | 841,20 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру,  соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1599,60 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Масловка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024 елның 23 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының Масловка авыл җирлегендә
2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2964,70 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2964,70 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 841,20 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1599,60 |
| Җәмгысе: | **8370,20** |